ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**14 ноябрь 2019 ел** **№ 841**

2020 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе кыйммәте нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөрткәндә автомобиль транспортыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, 2010 елның 5 июлендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнамәләрне раслау турында» 545 номерлы карарына ярашлы, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- 2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын;

- Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе                                        А.Ә. Шафигуллин

А.В. Сучкова
2-80-12

Ютазинского муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
расланды
__.__.20__ № ____

2020 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сум | автотранспорт чарасы юл узуының бер километрына ставка, сум |
| КАВЗ | 116 398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116 656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110 767 | 30,41 |
| УАЗ | 110 314 | 29,04 |
| FIAT | 110 057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110 572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110 829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119 128 | 35,31 |

Ютазинского муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
расланды
__.__.20__ № ____

# Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмә

## Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар (алга таба - муниципаль хезмәт) белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының факттагы юл узуы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда, автотранспорт чараларының факттагы пробегы турындагы мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында эшләнгән автотранспорт чарасының факттагы узышы буларак Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. $i$ муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\ m}$ - $m$ моделендәге автотранспорт чараларының фактта узган юлы, километр;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда бер автотранспорт чарасына ташуны оештыру бәясе нормативының ставкасы, сум;